
# ТРАНСПОРТ ТУРЫНДА ТАБЫШМАКЛАР

Вафина Лилия Ильфировна

# САМОЛЕТ

Канаты бар җилперми,
Эче җылы, җил тими.
Корыч йөрәкле кош ул,
Безнең яраткан дус ул.



Гаҗәп  матур чикерткә.
Күзләре- пыяла
Канатларын әйләндерә
Җилләрне бик тиз тоя.



**ВЕРТОЛЕТ**







Офыкта болыт юк.
Ләкин һавада ачылды зонтик!
Берничә минуттан җиргә төште ......




**ПАРАШЮТ**



# МАШИНА

Дүрт дөбердек,
Ике елтырык,
Бер ыжгырык.



# ПОЕЗД

Уф-пуф сулар,
Уфтанса да алып китәр,
Барыр җиренә җитәр.




Ике көпчәкле арба,
Атсыз да алга бара.

# ВЕЛОСИПЕД











Арбасы бар, арты юк,
Тәртә мазар заты юк.
Тоткасына кулың тисә,
Атны да узып китә.

## АВТОБУС



Маңгаенда мөгезе бар,
Боргаласаң -үкерә
Менеп атлансаң биленә
Җилдән җитез йөгерә.

## МОТОЦИКЛ





Балык түгел – суда йөзә
Туктаусыз төтен бөркә,
Эченә кереп утырсаң
Су буйлап алып китә.

# ПАРОХОД

